# КАРАР

## Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлеге составына кергән Ачы торак пункты гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2025 елның 23 октябреннән № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Иске Чишмә авыл җирлегенең Ачи торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән «2026 елда үзара салым кертүгә ризалыгыгыз бармы» мәсьәләсе буенча гражданнарның җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәләре төзелде. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (гидрант сатып алу, урнаштыру);
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт валчык сатып алу яисә)

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә ярашлы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә - гражданнар җыенында 85 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 48 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен - гражданнар җыенында 48 катнашучы тавыш бирде; "Юк" позициясе өчен тавыш бирде - җыенда 0 катнашучы.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1.Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлеге составына керүче Ачи торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2.Түбән Кама муниципаль районының Иске Чишмә авыл җирлеге торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә ризалык бирәсезме дигән сорау буенча карар кабул итәргә. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (гидрант сатып алу, урнаштыру);

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (асфальт валчык яисә вак таш сатып алу).

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына, Иске Чишмә авыл җирлеге сайтына урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Чишмә авыл җирлеге башлыгы Е.Ю. Ермаков

«Совет Старошешминского сельского поселения Нижнекамского муниципального района Республики Татарстан»